

**/Безнең сәяхәтләр/**

## Сукыр Чирмешәнгә сәяхәт

29 нчы май көнне, мәктәптә кабул ителгән гадәт буенча, ел фасылларының барысында да уздырыла торган табигатькә сәяхәткә чыктык. Без авылыбызның төрле болын-аланнарында ял итәргә өлгердек инде. Быел исә үзенең матурлыгы белән сокландыра торган “Болгар куаклыгы” аланында рәхәтләнеп ял иттек. Бу якларның һәр урыны кабатланмас ямьгә ия. Авылыбыз җирләренең бу почмагында үзебезнең Аксубай районы белән күршедәге Алексеевск һәм Чистай районнарының чикләре кисешә. Ул районнарны безнең җирләрдән Чирмешән елгасы аерып тора.

Бездә Чирмешән генә түгел, аның адашы Сукыр Чирмешән дә бар. Менә без бу юлы Сукыр Чимешән елгасында көймәдә йөздек. Аның яр буйлары тагын да гүзәлрәк икән. Рафик абый безгә йөзәр өчен көймә дә алып килгән иде. Ышыкка кереп ял итәргә дип палаткалар да кордырды. Моның өчен Рафик абыйга аерым рәхмәт әйтәсе килә. Балачакның һәр мизгеле истә калырлык булсын өчен, ул безне нинди генә сәяхәтләргә алып бармады инде. Ләкин әллә кайларга бармыйча да, үзебезнең туган ягыбызда рәхәтләнеп ял итү мөмкинлек тудырганы өчен дә яратабыз без аны.

Рафик абый гадәттәгечә, безгә бу урыннарның атамалары һәм тарихлары турында да сөйләп үтте. Без ярларына килеп туктаган су “Сукыр Чирмешән” дип, Чирмешән елгасының иске үзәне булганлыгыннан һәм баш-башы күмелеп томаланганга күрә атала икән. Борынгы язмаларда аңа карата “Үрлемән” дигән атама да кулланылган диде Рафик абый. Биредәге куаклыкка “Болгар” атамасы моннан ерак түгел шундый исемдәге авыл булганлыкка күрә кушылган. Әлеге Болгар посёлогы 1920нче еллар ахырында Иске Әдәм авылыннан аерылып чыгып, 1960нчы еллар башына кадәр яшәгән. Ләкин бу авылга “Болгар” дигән тарихи исемнең бирелүе тикмәгә генә түгел икән. Без утырган җирдән 100 метрлап ераклыктагы калку урында борынгы болгар заманында бер авыл булган. Ул тирәгә төнлә килгән кешеләрнең адашуын Рафик абый әлеге борынгы авылның зиратына бәйле булырга мөмкин дип аңлатты. Һәм безгә бә бу якларга ялгыз гына төнлә килмәскә киңәш итте.



Болынга чыккач, һәрберебез үзенә ошаган, күңеленә хуш килгән шөгыль белән мәшгуль була инде. Монда берәүләр балык тотты, кемдер көймәдә йөзде. Футбол уйнаучылар, чәчәк җыючылар да булды. Укытучы апалар һәм абыйлар сәяхәткә чыккан саен безне тәмле уха һәм компот белән сыйлыйлар. Бу юлы да табигатьтә, учакта пешкән ризыклар телне йотарлык иде. Көлдә пешкән бәрәңгесе биграк тә тәмле булды.

Укытучыларыма күзләребезне телефон экраннарыннан аерып, файдалы ял иттерүдәре, матурлыкны күрергә өйрәткәннәре өчен зур рәхмәт. Мондый чараларда дусларың белән тагын да якынаясың. Табигатьтә югалып калмаска да өйрәнәсең. Өйдә генә куллана торган төрле катлаулы техникаларсыз да үзеңә ризык әзерләп булганын да өйрәнәсең. Табигать белән һәрвакыт бергә булырга кирәк!

*Ләйсән Закирова, VI сыйныф укучысы*

**/Күңелле тәнәфес/**

## Ни диләр?

Мунчаладан бау ясауны ... диләр,
Түбәлән кар төшерсәң дә, ... диләр,
Искергән бер стенаны җимерсәң дә,
Ишкәк белән көймәдә йөзеп йөрсәң дә,
Һаман да шул бер үк төрле исемлиләр.

Атка атланып, кызу барсаң, ... диләр,
Пальтоңның итәген дә ... диләр.
Чалгы белән үләннәрне кыркысаң да,
Себерке белән мунчада парлансаң да,
Һаман да шул бер үк төрле исемлиләр.



**/Котлыйбыз!/**

Ямьле май аенда туган көннәрен билгеләп үтүче дусларыбыз **Сафиуллина Кәримәне** (VI сыйныф), **Вәлиева Мәрьямне** (VII сыйныф), **Шичкин Алины** (VIII сыйныф), **Шичкина Каринаны** (XI сыйныф) котлап, ныклы сәламәтлек, укуларында уңышлар телибез. Әти-әниләрегезнең горурлыклары булыгыз!

Башлангыч сыйныф укытучысы **Хәйруллина Рузилә апаны** да гомер бәйрәме белән котлап, ныклы сәламәтлек, иҗади уңышлар, озын гомер телибез.


**<u>Газетаны гамәлгә куючы</u> – Түбән Майна урта мәктәбе**
**<u>Мөхәррир</u> – Фәнүзә Гафиятуллина**
**<u>Редколлегия әгъзалары:</u> Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин**



# Мәктәп хәбәрчесе

**№5**
**(№56)**
**май**
**2024 ел**

**Түбән Майна урта мәктәбе газете**



**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**





**/Мөхәррир минбәре/**

## Саубуллашу бәйрәме

25нче май көнне мәктәбебездә "Соңгы кыңгырау" чыңлады. Соңгы кыңгырау финиш сызыгын ясый, барлык дәресләрләргә, контроль эшләргә һәм өй эшләрәренә, гомумән бөтен мәктәп тормышына нокта куя. Безнең мәктәптә кабул ителгәнчә, бу көн тамашасының әчтәлеген чыгарылышлар үзләре билгели. Быел мәктәбебездән дүрт укучы чыгарыла. Аларның өчесе XI сыйныфны, берсе IX сыйныфны тәмамлыйлар. Укучылар сафы елдан-ел кимүе генә күңелләрне шактый борчый.

Тантаналы өлешне укучылар моңсу җырлары белән башладылар. Ел саен, кайсы гына бала төрдә басып торса да, аны туган өебез кебек якын булган мәктәптән чыгарып җибәрү авыр була. Үзләренең сөйләгән шигырьләре дә , җырлары да һәркемне моңсу саубуллашу сәгатенә якынайта. Директорга сүз бирелгәч, ул уку елына нәтиҗә ясап, уңышлар һәм киләчәккә максатлар белән таныштырды. Чыгарылышларга алдагы тормышларында сынатмаска, туган җирләре өчен кирәкле белгечләр, чын шәхесләр булып җитлегүләрен теләде. Бәйрәмгә килгән район вәкиле Зәйнуллин Флүн Җәмил улы чыгарылыш сыйныф укучыларына һәм аларның ата-аналарына мөрәҗәгать итеп: «Кеше кайда гына, кем булып эшләмәсен, хезмәтне яратырга, җиргә якын булып яшәргә тиеш. Сезнең арада авылны, җиргә бәйле хезмәтне яратучы укучылар булуы сөендерә. Әлеге вакытта балалар алдында зур сынау тора. Ул да булса дәүләт имтиханнарын тапшыру. Ата-ана алдында яшьләргә дөрес юнәлеш биреп, киләчәктә үзләре яратып эшләрдәй һөнәр сайларга ярдәм итү бурычы куела», – диде ул. Аның сүзләренә Иске Әдәм җирле үзидарә җитәкчесе Хөснуллина Энҗе Мидхәт кызы да кушылып, укучыларны бәйрәм белән котлады, алдагы сынауларда уңышлар теләде. Иң борчылган кешеләребез – әниләр, балаларны котлап, изге теләкләрен җиткерделәр. Балаларның янәшәсендә булган укытучылары да аларга бары тик уңышлар гына теләделәр. Укучыларны олы юлга озатучы хәзерге сыйныф җитәкчеләре Алсу апалары дөрес максатлар, теләкләр куярга өндәде



Чыгарылыш сыйныф укучылары белән бергә, бәйрәмдә IV сыйныф укучылары да чыгыш ясады. Алар башлангыч мәктәп белән саубуллашты. Аларга да сыйныф җитәкчеләре Гөлшат Закирова югары сыйныфларда сынатмаска, тырыш булырга өндәде. Барлык тәрбикләү сүзләреннән соң бәйрәм шигъри юллар, җыр белән үрелеп, соңгы кыңгырау истә калырлык итеп, чыгарылышлар биюен биеделәр. Укучыларыбызга алдагы юлларында бары тик хәерле киләчәк кенә телибез! Әти-әниегез, туган авылыгыз, мәктәбегез өчен горурлык булыгыз!

*Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир*

**/Рәсми хәбәрләр/**

## Уку елы нәтиҗәләре

Быелгы уку елын мәктәптә 41 укучы тәмамлады. 38 балага чирек билгеләре чыгарылды. Гомуми белем сыйфаты 71% тәшкил итте. Отличниклар: II сыйныфтан **Гафиятуллина Руфинә**; III сыйныфтан **Закиров Инсаф** белән **Камалов Илнур**; IV сыйныфтан **Нурматова Асия, Хусенов Дима**; VI сыйныфтан **Закирова Ләйсән**; VII сыйныфтан **Гафиятуллин Фаил.**

Мәктәптән тыш чаралар буенча югары нәтиҗәләргә ирешкән укучылар:

- фән олимпиадаларында – **Нурматова Асия** (IV сыйныф), **Закирова Ләйсән** (VI сыйныф), **Гафиятуллин Фаил** (VII сыйныф); **Гафиятуллин Самат , Нурматова Зәйнәп** (X сыйныф)
- спорт юнәлешендә – көрәшчеләр **Замалетдинов Зөлфәт**, **Сәгъдиев Рәмзис**, **Хәбибрахманов Абдулла** (V сыйныф), **Шичкин Али** (VIII сыйныф), шахматчы – **Гафиятуллин Фаил** (VII сыйныф);
- әдәбият һәм сәнгать юнәлешендә – **Закиров Инсаф** (III сыйныф), **Нурматова Асия** (IV сыйныф), **Насыйрова Кәүсәр** белән **Закирова Ләйсән** (VI сыйныфлар), **Залиева Вәсилә** (VII сыйныф), **Шичкина Карина** белән **Морадимов Илсур** (XI сыйныфлар).

*Илдар Сафиуллин, уку-укыту буенча директор урынбасары*




*/Безнең бәйрәмнәр/*

## *Шагыйрә Алсу Нәҗминең иҗат кичәсе*

13 май көнне безнең мәктәптә авылыбызның Мәдәният йорты мөдире, шагыйрә, җырлар авторы Алсу Нәҗминең “Туган телем – хәзинә” дип исемләнгән иҗат кичәсе мәктәптә булып узды. Без, укучылар, бу чарага алдан әзерләндек. Авторның иҗатына карата иллюстрацияләр ясадык. Рәсемнәребезне дә, авторның китаплары һәм кул эшләнмәләре белән бергә күргәзмәгә куйдык.

Бәйрәмдә шагыйрәнең 18 еллык иҗаты дәверендә биш китабын чыгарганлыгы, Алексеевский язучыларының сугыш турындагы шигырьләрен җыеп “Сүнмәс хәтер” дип исемләнгән китабын бастыруын, шигырьләре якташлар җәмгыятенең өч җыентыгында дөнья күрүен, 20 җыр авторы булганлыгын ишеттек. Шуларның кайберләренә көйне дә үзе язган. Бәйрәмдә автор башкаруында ул җырлар яңгырады.



Кичә Алсу Нәҗминең үз шигыре белән башланып китте. Тәрҗемәи хәле, нәселе, иҗаты турында алып баручы тәртипләп таныштырып барды. Гаиләсеннән әнисе дә кызының уңышына сөенеп, бер мөнәҗәт башкарды. Бертуган апасы, авыл җирлеге җитәкчесе Энҗе апа да сеңелесе өчен горурлануын яшермәде. Кичәгә район башлыгы Камил Камал улы Гыйлманов, район мәгариф бүлеге җитәкчесе Зәйдуллина Рәмзия Сәлих кызы килүе авылдашыбызның күренекле булуына бер дәлил булды. Кунаклардан рәссамнар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Бөтендөнья татар конгрессының Аксубай бүлеге җитәкчесе Нурхаматова Әлфия Рәшит кызы, Казаннан




Таткультресурсцентр методисты Миләүшә Насыйбуллина, шагыйрә Нәҗибә Сафина, меценат Суниева Рузалия Әхмәтгалиевна, Алексеевский районы Милләтләр ассамблеясы җитәкчесе Гатина Рафидә Мәүлетшәриф кызы, Алексеевский районы Коры Көрнәле җирлеге башлыгы, авылның “Ак калфак” оешмасы җитәкчесе Казакова Дилбәр Бәдретдин кызы да бу чараның кунаклары булды. Һәрберсе Алсу Нәҗминең иҗатына тукталып, җәмәгать эшләрен дә санап китеп, кичәбезгә нур өстәделәр. Укучылар тарафыннан “Карлыгач һәм карга хикәяте”сәхнәләштерелде. Кызлар Алсу Нәҗминең әбиләре язган “Рәсүлулла туды” мөнәҗәтен яңгыраттылар.

Кичәдә бүләкләүләр дә булып узды. Мәктәп директоры Рафик абый Алсу Нәҗмигә алар нәселенең шәҗәрәсен бүләк итте. Мәгариф бүлеге җитәкчесе Рәмзия апа Зәйдуллина узган уку елында Туган тел буенча уздырылган бәйгеләрдә җиңүче булган укытучылар һәм укучыларга Рәхмәт хатлары тапшырды. Безнең авыл мәктәбендә узган уку елында мондый зур чара икенчесе булды.

***Зәйнәп Нурматова, X сыйныф укучысы***

## *Җиңү бәйрәме*



9 Май – иң тантаналы, кадерле, һәм шул ук вакытта бик моңсу да бәйрәмнәрнең берсе. Күпме генә вакыт үтсә дә, илебез азатлыгы өчен көрәшкән яугирләрне һәрвакыт хөрмәт белән искә алачакбыз. Үсеп килүче буынга патриотик тәрбия бирү – бүгенге җәмгыять өчен иң төп бурычларның берсе булып тора. Бу төшенчә бала күңелендә Туган җиреңне һәм илеңне ярату, үз халкының тарихы, үткәне белән горурлану хисләре уяту дигәнне аңлата.

Шул максаттан безнең балалар бакчасында һәм мәктәптә төрле чаралар үтте. Иң беренче "Җиңү тәрәзәләре" акциясендә катнаштылар. Бу көнгә башлангыч сыйныф укучылары сыйныф тәрәзәләрен бизәп куйдылар, матур открыткалар әзерләделәр. Һәйкәл янында узган тантаналы тамашаны урта сыйныф укучылары әзерләде. Безнең тыныч тормышыбыз өчен корбан булган авылдашларны барлап, искә алып, “Үлемсез полк” акциясендә исем, фамилияләре яңгырады. Хәрби формадан һәйкәлгә сакка баскан егетләребезгә киемнәре бик килешсә дә, сугыш афәтләрен күрмәсеннәр, тормышлар тыныч кына барсын диясе килә.

***Зәйнәп Нурматова, X сыйныф укучысы***



*/Мәктәп тормышы/*

## *19 май – балалар иҗтимагый оешмалары көне*


Бу истәлекле дата, башка бик күпләре кебек үк, үз тарихын совет заманнарыннан алып бара. Элек ул пионерия көне буларак билгеләп үтелгән. Бүгенге бәйрәм балалар иҗтимагый хәрәкәтендә катнашучыларның дуслыгын, балаларның һәм өлкәннәрнең үзара аңлашуын символлаштыра. Әлеге вакыйга уңаеннан безнең мәктәптә тәрбия буенча директор киңәшчесе Динә апа укучыларга дәрес үткәрде. Анда без пионерларның кем булуы, нәрсә эшләүләре һәм нинди кыйммәтләр яклаганы турында сөйләштек.

Тарихка күз салсак, 1922 елның 19 маенда ВЛКСМның 2нче Бөтенроссия конференциясе пионер отрядларын төзү турында карар кабул иткән. Шул көннән бирле 19 май СССРда Пионер оешмасы туган көн буларак бәйрәм ителгән. Колхозлашу, Бөек Ватан сугышы еллары, авыр сынау, көрәш, Бөек Җиңү... Әлеге авыр сынаулар дәверендә яшь ленинчылар өлкәннәр белән беррәттән иген иккән, станок артларына баскан, корал тотып фашистларга каршы да барган. Герой пионерлар исемнәре алтын хәрефләр белән тарихка язылган. Пионерлар Бөек Җиңүне якынайту һәм сугыштан соң илебезне аякка бастыру өчен зур тырышлык күрсәткәннәр.



Әниләрнең әле пионер чакларын искә алганы да еш ишетелә. Хәзерге балалар оешмалары әгъзаларыннан аермалы буларак, пионерлар муеннарына кызыл галстуклар бәйләп йөрегәннәр. Тантаналы чараларда быргыда уйнап, барабан кагып, кызыл байраклар күтәреп чыкканнар. “Әзер бул!”, “Һәрвакыт әзер!” – дигән, кулны баш өстенә күтәреп әйтә торган оранныры булган. Элек безнең мәктәп укучылары 19 май хөрмәтенә болынга экскурсиягә чыга торган булганнар.

***Самат Гафиятуллин, X сыйныф укучысы***



*/Укучылар иҗаты/*

## *Җәй рәхәте*

Тиздән матур, без бик көткән җылы җәй җитә. Каникул! Бу сүзнең рәхәтлеген безнең кебек укучылар гына аңлый инде. Җәй ул – иркенлек, җәй ул – табигать, ул – үзе бер дөнья. Без аны шулкадәр озак көтәбез, башта әллә нинди хыяллар була. Ял итәсең, дәрес әзерли торган өстәлне дә җыеп куясың, чөнки әле ул сиңа тиз генә кирәк булмый. Менә шул соңгы дәрестән соң туган шатлыкны берничек тә аңлатып булмый.

Шундый матур вакытта каникул биргәннәренә рәхмәт. Җәйнең бер көнендә кыр юллары буйлап велосипедта җилдерәсең. Ә кәрзиндә әнигә дигән кыр чәчәкләре. Ул да инде җәйнең матурлыгын минем аша күрсен әле дисең! Велосипедта йөргәндә җылы җил күкрәкне ярып күңелгә үк керә бит. Кайбер эссе көннәрдә әни белән әти печән җыярга уяталар. Күз ачылмый ятканда торырга авыр кебек булса да, кошлар сайравы баш миенә үтеп кергәч, йокылар ачыла. Иртә торганыңа шатланасың. Чөнки иртәнге саф һава, тынлык бернинди шифа белән чагыштыргысыз була. Иртәнге кояшка күзне кыса-кыса сәлам бирәсең. Кояш юри күзне кыса, күз кысылгач елмаясың. Ул, димәк, елмаерга да, елмайтырга да ярата.

Печән җыелып беткәч, әни рәхмәт йөзеннән су коенырга да алып бара, туңдырма белән дә сыйлый. Кояшта пешкән тәннәр, эш белән туган тире тамчылары да елгада суыналар. Тагын бер рәхәт дисең. Аннан тиздән көтү чираты җитә. Монда инде тагын болытларны күзәтәсең. Анда фантазияң җитсә, әллә нинди фигуралар, хайваннар күрергә була. Аларның ашык-пошык йөзгәннәрен карап, тагын елмаясың. Чөнки көтүдә мин ашыкмыйм, ә алар ашыгалар. Менә шундый хыялый инде мин.

Берзаман шәһәрдән кунаклар кайта. Алар киткәндә сине дә кунакка алып баралар. И, шәһәр җәе берни түгел инде. Яшел чирәм клумбада гына. Ә бездә ятып тәгәрисең. Таштан бәреп торган эссе дә рәхәт түгел. Авылдагы кебек ирек тә юк. Ә авыл җәе... Шуңа да инде авылдан китәселәре килми шәһәрдән кайткан кунакларның. Үзем баргач аңладым менә. Авылда минем өчен бердәнбер уңайсызлык – дусларым юк. Авыл өчен мин бердәнбер бала. Авылымның матурлыгын да, җәйнең рәхәтен дә берүзем тоеп, күреп йөрим. Әле дә ярый туганнар кайта! Әле ярый элекке күршеләр кайта. Очрашасың, алар белән сөйләшәсең, күңелгә тагын рәхәт булып китә!

***Камил Тәхфәтуллин, VI сыйныф укучысы***